**Тема:** Кеше кешегә туган, иптәш, дус.

**Максат:**

1. Укучыларны “Кеше кешегә туган, иптәш, дус” дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп аларда изгелек, рәхимлелек, шәфкатьлелек кыла белү сыйфатлары, башка кешеләргә карата мәхәббәт, ихтирам хисе тәрбияләү.
2. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.
3. Дөньда бар кешеләргә карата ярату хисе, михербанлык тәрбияләү.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**

- Кеше Аллаһ яралткан (бар иткән) һәрнәрсәне яратырга һәм кадерләргә, аларга яхшылык кылырга тиеш икәнен аңлау.
- Мөселманның үзеннән дә, сүзеннән дә, гамәленнән дә башкаларга зыян булмас икәнен белү.

**Эпиграф**:

- *“Нәрсәгә охшаган кешелеклелек, кешеләрне яратуы? Башкаларга ярдәм итәр өчен аның кулы бар, мохтаҗлар янына ашыгыр өчен аның аягы бар, ярлыларны күрер өчен аның күзе бар, кешеләрнең ыңгырашуын ишетер өчен аның колагы бар. Менә нәрсәгә охшаган икән ул кешеләрне яратуы”. / Августин/*
- *“Мөселманның үзеннән дә, сүзеннән дә, гамәленнән дә башкаларга зыян булмас”.*

## Дәреснең барышы

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Кечкенә генә ике хикәяне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын әйтеп бирегез:

- *Японияда җир тетрәгәннән соң исән калган кешеләрне эзләп табып коткаручылар чираттагы җимрек йортның стена ярыгыннан бер хатынның гәүдәсен күреп алалар. Бераз алга киткән гәүдәнең торышы бик сәер иде, кеше, бертөрле, тезләнеп дога кылган, ә куллары белән нәрсәдер тотып яки, кочаклап торган шикелле кыяфәттә иде. “Исән түгел микән?”- дип өметләнеп, китеп барган җирдән кире борылып, хатынны бик зур саклык белән актарып чыгаралар. Өстән коелган ташлар аның башына, аркасыңа зыян китереп, яшәргә өмет калдырмаганнар, ләкин салкын гәүдә астында барлыкка килгән куышта коткаручылар чәчәкле одеялга төрелгән 3 айлык исән- сау, берни белмичә йоклап яткан баланы күрәләр. Кечкенә малайны табибка алып баргач, одеял эченнән кәрәзле телефон килеп чыга,экранда ананың улына язылган ахыргы сүзләр: “Әгәр дә исән калсаң, беркайчанда онытма: мин сине шундый яратам”. Кулдан кулга күчкән телефон язуы бер ирне дә елатмыйча калдырмаган.*

- *Армения. Спитак шәһәре. Кояшлы матур көн. Ата- аналар эш урыннарында, бала-чагалар- мәктәптә. Ләкин шул көнне дәресләрен ахырына кадәр алар укып бетерә алмаганнар. Кинәт кенә куркыныч тавышлар ишетелеп, мәктәп бинасы селкенә башлый, стеналар ярылалар... Балалар, укытучы апалар куркуларыннан кычкырышалар һәм һәрбер кеше үз- үзен коткарырга теләп, урамга йөгереп чыгарга тырыша.*
  *10 сыйныф укучысының класстан атылып чыккан вакытта, баскычтан йөгереп барганда, 1 этажда адашып, елап торган кечкенә генә малайны күреп ала. Артка борылып караса, 1 сыйныф укучылары кая барырга белмичә, өелешеп торалар. Егет башта бер класс укучыларын, аннары – икенчесен, юл күрсәтеп, җитәкләп, дигәндәй, балаларны урамга алып чыга. Ләкин тагын бер сыйныф әле җимерелеп барган бина эчендә.Тизрәк! Инде ахыргыларын чыгарып, артларыннан озатып барганда, баскыч җимерелә. Ул көнне Спитак шәһәрендә таш астында күмелеп калган кешеләр саны 25 менгә җитә. Ләкин алар арасында аның шикелле гомеренең*

*ахырыгы мизгелләрдә башкаларны коткару турында уйлап һәлак булган кешеләр саны шул хәтлеүк күп түгелдер.*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Хикәяләрне берләштергән теманы ачыклагыз.
- Ике хикәяне дә берләштергән тема – ул, әлбәттә, батырлык, михербанлык. Үлемгә аз гына вакыт калкач та, башкаларны, үзеңннән дә мохтаҗрак кешеләр турында уйлау, ләкин бүгенге дәрес михербанлык турында гына түгел. Уйлап карагыз: ике хикәянең аермасы нидә?
- Беренче хикәядә ана үзенең баласын коткарып корбан була. (Икенче хикәядә егет үзенә туган, бәлки, таныш та булмаган балаларга ярдәм итеп, һәлак була).
- Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (“Кеше кешегә туган, иптәш, дус”)

**III. Уку мәсъәләсен чишү.**

***1. “Ни өчен кешеләр бер- берсенә иптәш, дус кына түгел, хәттә туган шикелле якын булырга тиеш?”- дигән сорауга җавап табу.***

- Чөнки шулай булганда гына, кешегә үзенә авырлык килгән чакта кемнеңдер ярдәменә өмет итеп була икән. Башкаларга булышмаган кешене, үзе турында гына уйлаган бәндәне хөрмәт тә итмиләр, аңа ярдәм кулын да сузарга бик ашыкмыйлар, чөнки яхшылык та, начарлык та, һичшиксез, үзеңә кире әйләнеп кайта.
- Авыл җирендә күрше- иң кадерле кешеләрнең берсе булып тора. Аның белән дус булып, тату яшисең икән- син бәхетле, ызгышып- талашып ятасың икән- икегез дә кызганыч хәлдә.
- Ни өчен безгә һәр кеше белән (җайлымы ул- көйсезме, акыллымы ул- ахмакмы) уртак тел табып яшәргә йөрәнергә кирәк? Бу бик әһәмиятле һәм авыр мәсъәлә булса да, уйланып карыйк. /Җаваплар/

***2. Төркемнәрдә эшләү.***

**1нче бирем *“Яхшы сүз турында”***

Яхшы сүзне җаның тели синең,
Начарлыктан күңел көрсенә.
Ә син үзең андый яхшы сүзне
Әйтәсеңме башка кешегә?

Р. Фәйзуллин

- Чыннанда, бөтен кешенең матур, җылы сүз ишетәсе килсә дә, еш кына тупас, әдәпсез сүзләр ишетергә туры килә. Р. Фәйзуллин биргән сорауга өчтән генә һәр беребез җавап бирик әле үзебезгә: “Ә син үзең андый яхшы сүзне әйтәсеңме башка кешегә?”

/Укучылар бераз уйланып алсыннар/

**2нче бирем *«Башка кешеләр белән дус, туган шикелле тату яшәр өчен, алар белән ничек итеп аралашырга кирәк?”- дигән сорауга җавап бирү.***

- Безнең тирәдәге кешеләр белән әдәпле, матур итеп сөйләшә белү бик тә әһәмиятле.
- Башка кешеләр белән дус, туган шикелле тату яшәр өчен, алар белән ничек итеп аралашырга кирәк?” /Җаваплар/

**3нче бирем *“Чагыштырыйк әле!”***

- Сезнең җавапларыгызны безнең фикерләр белән чагыштырыйк:
    - Кешеләргә елмай, ачык йөзле бул- сине яратырлар.
    - Үзеңне зурга куйма, башкалардан акыллырак дип исәпләмә, алай эшләсәң- синнән көләрләр.

- Үзеңне һәрвакыт дөрес, хаклы дип уйлама- син дә ялгышасың.
- Кешеләргә ярдәм итәргә ашык- савапны күбрәк җыярга тырыш.
- Сиңа ярдәм иткән кешегә рәхмәтеңне әйтергә онытма-шөкер итүчеләрдән булырсың.
- Юк- барга үпкәләмә, гафу ит- сине дә гафу итәрләр.
- Мөмкин кадәр күбрәк изгелек, яхшылык кылырга тырыш- кире кайтыр.
- Изгелекне кешеләр өчен эшләгән шикелле булсаң да- рәхмәте, савабы үзеңә була.
- Кешеләрнең уңай, яхшы якларын күрә бел- алар сиңа тагын да әйбәт булырлар.
- Сине үпкәләтсәләр- үч итә күрмә: ул кеше болай да мескен- Аллаһ каршысында аның сине рәнҗеткән өчен җавап бирәсе бар.

**4нче бирем “*Изгелекләр генә кылып яшик”***

**-** Яши-яши берәү дә үз гомеренә әйләнеп карамыйча булдыра алмый, - ди Аяз ага Гыйләҗев. Гомерләр заяга үтмәсен. Ә исән чакта, кеше дигән исемне йөртү – бәхет, яшәү – шулай ук бәхет, дөнья – матур, киң. Әнә шундый якты дөньяда бер-береңә изгелекләр генә кылып яшә дә яшә икән ул. Чөнки **кеше кешегә туган, иптәш, дус.** Кешеләрнең зарына колак салыгыз әле, тирә- юндәгеләргә игътибарлы булыгыз. Кешеләргә ярдәм кулыгызны сузарга әзер торыгыз! Яхшылык җирдә ятмас! Башкаларга булыша алуыгызга сөенеп яшәгез. Энҗе Авзалова “Изгелек догасы” шигырендә болай ди:

Дога белмим дисең нигә?
Яхшылык – үзе дога!
Бар кеше изгелек кылса,
Яктырыр иде дөнья.
Изгелек ул – беркайчан да
Тузмый торган хәзинә.
Яхшылык эшлик һәрвакыт,
Ул үзе изге дога!
- Тормыш яшәү матурлыгы, шәфкатьлелек, кешелеклелек, миһербанлык белән дә матур.

**5нче бирем *“Танылган шәхесләргә сүз бирик”***

- *Чын бәхет, рәхәт- һәрбер кеше башка кешеләрнең ярдәменә мохтаҗ һәм сез башкаларның ярдәмен көткән шикелле алар да сезнең ярдәмегезне көтеп торганын- аңлауда. /Француз язучысы Д.Дидро/*
- *Нәрсәгә охшаган кешелеклелек, кешеләрне яратуы? Башкаларга ярдәм итәр өчен аның кулы бар, мохтаҗлар янына ашыгыр өчен аның аягы бар, ярлыларны күрер өчен аның күзе бар, кешеләрнең ыңгырашуын ишетер өчен аның колагы бар. Менә нәрсәгә охшаган икән ул кешеләрне яратуы. / Августин/*

- Танылган шәхесләр сүзен ничек аңлыйсыз? /Фикерләшү/

**6 нче бирем *“Эпиграф өстендә эш”***

- Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграф итеп тактага яздык. Җөмләне хор белән кабатлыйк һәм үзебезнең йөрәкләребезгә гомер буена салыйк, беркайчанда онытмыйк.

**7нче бирем *“Мин тормышта дөрес яшәү рәвеше алып бараммы?”***

- Укучылар, без бу дәрестә бик күп сөйләштек. Әдәплелек, игелеклелек, кешелеклелек. Бер мизгелгә генә тукталыйк та, үз-үзебезгә сорау бирик.
- Мин тормышта дөрес яшәү рәвеше алып бараммы?
- Күрше хакын хаклыйммы? Әти-әниемә, туганнарыма, дус-иптәшләремә мәрхәмәтлеме, аларны рәнҗетмимме?
- Киләчәккә дөрес юлны таба алырмынмы?
- Туган ягымны яратаммы, табигатькә карата мәрхәмәтлеме?

- Тел, милләт язмышы өчен борчыламмы?
- Бу дөньяда язмыш тарафыннан кимсетелгәннәр барын онытмадыммы?
- Әйе, укучылар. Бу сорауларга сез гомер буе җавап эзләп, үз алдыгызга шушы сорауларны куеп яшәргә тиешсез. Һәркемнең бәхетле булырга хакы бар. Сәламәт буласың килсә, кешеләр бәхетеннән көнләшмә, бәхетсезлегеннә сөенмә. Кеше булып кала бел! Тормыш әлифбасын гомер буе өйрәнергә тырыш. Тауларга карап, Тау булмасаң да, Таңнарга карап, Таң булмасаң да, Кешегә карап, Кеше була бел – Олы җаныңның ише була бел! (Ф. Яруллин).

**3. Изге Коръән китабыннан**

- Аллаһ Тәгалә әйтте:

- ***“Яхшылыкта һәм тәкъвалыкта бер-берегез белән ярдәмләшегез. Гөнаһ һәм дошманлыкта исә бер- берегезгә ярдәмче булмагыз. Аллаһтан куркыгыз.... “***
- ***“Аллаһка сыенып ярдәм сораган кешегә ярдәм итегез, кешенең яхшылыгына яхшылык белән җавап кайтарыгыз».***

**4. Хәдисләр**

- Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең хәдисләрен укып, үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:

- ***“Сезгә иң хәерле һәм иң начар кеше турында хәбәр биримме? Иң хәерлесе бер явызлык кылмаган, гел яхшылык эшләп йөргән кеше. Вә иң начар кеше- яхшылык кылып йөресә дә, аның начарлыгыннан берсе дә имин түгел”.***

- Хакыйкый мөселман кешесе бер явызлык кылмаган, гел яхшылык кылып йөрүче кешеләр нең берсе. Ул бик яхшы белә: яхшылык аяк астында аунап ятмый, һәрбер изге эш өчен бу дөньяда да, теге дөньяда да әҗере булачак. Бу дөньяда кардәшенең кайгысын җиңеләйткән кешегә Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендәге кайгыларын җиңеләйтер. Мохтаҗлыкта яшәгән кешегә ярдәм итүче адәмнең Аллаһы Тәгалә ике дөньяда да хәлен җиңеләйтер.
- Һич шиксез, сиңа яхшылык эшләгән кешегә рәхмәтеңне белдертү, яхшылык белән җавап кайтару- зарури. Ислам күзлегеннән чыгып эш итәргә кирәк, ягъни яхшылык иткән кешегә җавап кайтару кешенең кәеф, күргән яхшылыкның әз яки күп булуына һ.б. бәйле булмаска тиеш. Кылган яхшылыгы әз булса да күп булса да, яхшылык кылу факты үзе генә дә иң изге теләкләргә, иү матур җавапларга лаек, иң мөһиме аны җавапсыз калдырмау.
- Ислам шулай дип өйрәтә: кешенең яхшылыгына рәхмәтле була белгән бәндә генә Аллаһка камил шөкер итә белә. Бу дәрәҗәгә күтәрелә алмаган кешенең эчке дөньясы көфран, шөкерсезлек белән тулган һәм бу- бөтен нигъмәтләрнең Хуҗасы булган Аллаһы Тәгаләгә шөкер итә белмәвенә дәлил. Шуңа күрә Пәйгамбәребез галәйһиссәләм бу хакта шулай ди:

- ***“Кешеләргә рәхмәтле була белмәгән кеше Аллаһка да рәхмәтле була алмый”.***

- ***«Дустыңны уртача ярат, чөнки ул беркөнне синең дошманыңа әйләнергә мөмкин. Дошманыңны да уртача дошман тот, чөнки ул беркөнне синең дустыңа әйләнергә мөмкин».***

- Кемне дә булса дус итеп тотсаң, аны үзеңә сакланып дус ит, чөнки беркөнне бер-берегезгә ачуланышып, аерылышырга туры килер дә, шул вакытта элек аңа сөйләгән эч серләрең өчен оялып калырга һәм аны эчкерсез дус итеп йөргәнең әрәмгә китәргә мөмкин. Дошманың белән дә саклану һәм тигезлек саклапаралаш. Чөнки, беркөнне шул ачуланышкан кеше белән дуслашырсың да, элек аның белән артык кырыс булганыңа үкенерсең.
- *Кыскасы, үзеңә дус булган кешегә эчеңдәге бар серләреңне сөйләп бетермә, дошманыңны да бик каты кимсетмә, чөңки дустың дошманга, ә дошман дуска әйләнергә мөмкин.*

- ***«Үзара дусларча мөнәсәбәттә булган, бер-берләренә мәрхәмәт итешкән һәм теләктәшлектә торган мөселманнар бер тән шикелле: тәннең кайсы төше***

***авыртса, уяулыкта һәм химаяда торучы бүтән әгъзалар да шуңа сызлану белән җавап кайтаралар».***

- Бу хәдисне ничек аңлыйсыз? /Фикерләшү/.
- Мөселманнар бер- берсенә бик якын булалар: берәрсенең хәле авырайса, аңа кайгы- хәсрәт килсә, башка мөселманнар аның хәленә кереп, ярдәмгә ашыгалар, чөнки “мөсеманнар бер тән шикелле” башка төшләр сызлаганга җавап бирәләр.
- Әммә шуны да белергә кирәк: без Аллаһы Тәгалә яралткан (бар иткән) һәрнәрсәне яратырга һәм кадерләргә, һәммәсенә яхшылык кылырга тиеш икән: хайваннарга, табигатебезгә, мөселманнарга һәм, һичшиксез, мөселман булмаган кешеләргә дә, чөнки тагын бер хәдистә болай диелгән:
- ***“Мөселманның үзеннән дә, сүзеннән дә, гамәленнән дә башкаларга зыян булмас”.***
- Изгелекләр эшлик, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алып, җәннәтле булырга ашыгыйк!

**V. Рефлексия (Йомгаклау).**

**-** Дәреснең темасын искә төшерегез.
- Кеше кешегә туган, иптәш, дус.
- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз?
- Кешеләргә ярдәм итәргә ашыгырга кирәк- савапны күбрәк җыярга тырыш.
- Юк- барга үпкәләмәскә, кешене гафу итергә.
- Сине үпкәләтсәләр- уч итә күрмә: ул кеше болай да мескен- Аллаһ каршысында аның сине рәнжеткән өчен җавап бирәсе бар.
- Мөмкин кадәр күбрәк изгелек, яхшылык кылырга тырышу кирәк.
- Кешеләрнең уңай, яхшы якларын күрә бел- алар сиңа тагын да әйбәт булырлар.
- Мөселманның үзеннән дә, сүзеннән дә, гамәленнән дә башкаларга зыян булмас.
- Кеше кешегә туган, иптәш, дус, чөнки без барыбыз да, Җир шарындагы кешеләр, Адәм белән Наваның балалары.

**VI. Өйгә эш:**

“Кеше кешегә туган, иптәш, дус” дигән темага җавап әзерләп килергә.